КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 декабрь г.Казань № 1604

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 декабрь, 1246 нчы, 2022 ел, 2 август, 749 нчы, 2022 ел, 5 декабрь, 1285 нче, 2022 ел, 26 декабрь, 1417 нче, 2023 ел, 24 апрель, 518 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Әлеге Тәртип максатлары өчен яңа инвестиция проекты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты бюджетының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдындагы бурычларын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган акчаларын гамәлгә ашыру максатларында инженерлык тикшеренүләрен башкаруга, проектлауга, проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатациягә кертүгә, шулай ук капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) юнәлдерелергә тиеш яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 нче карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1704 нче карары) белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджетының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдындагы бурычларын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган акчаларын гамәлгә ашыру максатларында инженерлык тикшеренүләрен башкаруга, проектлауга, проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатациягә кертүгә, шулай ук капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) юнәлдерелергә тиеш яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләренең 2 пунктында каралган өлкәләрдә гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

1.9 пунктта:

икенче абзацта «еллар буенча бүлеп,» сүзләрен «яисә проектны гамәлгә ашыру чорында, әмма Россия Федерациясе Бюджет кодексының 933 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән максатларга Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүләрдә каралган йөкләмәләрне тулысынча үтәү срогыннан ким булмаган вакыт эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетына бюджет кредиты бирү турында» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы үзенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы акты белән раслана торган яңа инвестиция проектлары җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;»;

2.2 пунктның беренче абзацында «5 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

2.4 пунктта:

дүртенче абзацта «(бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат)» сүзләрен «(башка вәкаләтле вазыйфаи зат);» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«еллар буенча инвестицияләр, федераль бюджетка салым керемнәре һәм аны гамәлгә ашырганда төзелә торган эш урыннары саны (ирекле рәвештә) күләме турында мәгълүматны, гамәлгә ашырылучы яңа инвестиция проектын техник-

икътисадый нигезләүне үз эченә алган инвестиция проектының гомуми тасвирламасы яисә яңа инвестиция проектын һәм аның максатларын кыскача тасвирлаган документ, шулай ук Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы билгеләгән форма нигезендә әзерләнгән төп техник-икътисадый параметрлар (яңа инвестиция проекты резюме), яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында кулланыла торган инфраструктура объектының куәте турында белешмәләр булган инфраструктура объекты буенча нигезләү белешмәсе кушымтасы белән (ирекле рәвештә);»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«еллар буенча бүлеп, яңа инвестиция проектын гамәлгә ашырудан федераль бюджетка түләнергә тиешле салым керемнәренең фаразлана торган күләме турындагы белешмәләр;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инфраструктура объектын төзүнең төгәлләнүен раслый торган документларның күчермәләре, шул исәптән инфраструктура объектын файдалануга кертү турындагы боерыкларның күчермәләре, 2021 елның 1 гыйнварыннан соң инфраструктура объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләрнең күчермәләре;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча сайлап алуда катнашучының гамәлдәге чыгымнарын раслый торган документларның күчермәләре (юридик затлар (индивидуаль эшкуарлар) белән эшләр башкаруга һәм хезмәт күрсәтүләргә шартнамәләрнең күчермәләре) яисә инфраструктура объектларын төзү өчен сатып алынган төгәлләнмәгән төзелеш объектларын сату-алу шартнамәләренең күчермәләре, беренчел документларның, шул исәптән күрсәтелгән шартнамәләрнең үтәлешен раслый торган бухгалтерлык документларының күчермәләре (КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларның күчермәләре, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләр күчермәләре, КС-11 формасы буенча төзелеш тәмамланган объектларны кабул итү актларының күчермәләре (подряд оешмасы белән килешү төзелгән очракта), универсаль тапшыру документы формасы буенча җиһазлар кабул итү-тапшыру турында актларның күчермәләре һәм (яки) ОС-15 формасы буенча җиһазларны монтажга кабул итү-тапшыру турындагы актлар нигезендә төзелгән монтажланган җиһазлар ведомостьлары реестры (башкарылган эшләрне кабул итү турында рәсмиләштерелгән актлар булмаган очракта), инфраструктура объектларын төзүгә гамәлдә тотылган чыгымнарны раслаучы документлар һәм сайлап алуда катнашучының вәкаләтле затлары тарафыннан имзаланган программалы смета комплексыннан файдаланып тапшырыла торган документлар реестры, яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка документлар)). Бухгалтерлык исәбенә КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актлар, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр хакы һәм чыгымнар турындагы белешмәләр беренчел исәпкә алу документлары буларак кертелмәгән очракта, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр актларының күчермәләре, башкарылган эшләр актларына аңлатмалар тәкъдим ителә, шул ук вакытта формалары унификацияләнмәгән күрсәтелгән документларда законнар нигезендә мәҗбүри реквизитлар булырга тиеш;»;

унбишенче абзацка «(сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән шартнамәләрне төзегәндә)» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзацка «(сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның унбишенче абзацында күрсәтелгән шартнамәләрне төзегәндә)» сүзләрен өстәргә;

унҗиденче абзацка «(сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның унбишенче абзацында күрсәтелгән шартнамәләрне төзегәндә)» сүзләрен өстәргә;

унсигезенче абзацка «(сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның унбишенче абзацында күрсәтелгән шартнамәләрне төзегәндә)» сүзләрен өстәргә;

егерме җиденче абзацка «әлеге пунктның,» сүзләреннән соң «шул исәптән программалы смета комплексын кулланып, xml форматында электрон рәвештә сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырыла торган» сүзләрен өстәргә;

2.7 пунктта:

беренче абзацта «Кәгазь чыганакта бирелә торган заявка тегелгән, номерланган, имзаланган булырга тиеш» сүзләрен «Кәгазь чыганакта бирелә торган заявкага кушып бирелә торган документлар тегелгән, номерланган, имзаланган булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 2.4 пунктының унберенче абзацында каралган заявкага кушып бирелә торган документлар сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвештә электрон чыганакта тапшырылырга мөмкин.»;

2.8 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заявканы бирү датасы дип сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы һәм вакыты санала.»;

«а» һәм «б» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.10 пунктта «заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән 10 календарь көн эчендә» сүзләрен «заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән җиш эш көненнән артмаган срокта» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Берничә яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында инфраструктура объектыннан файдаланган очракта, Субсидия күләме яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында кулланыла торган инфраструктура объекты куәтенең өлешен исәпкә алып билгеләнә.»;

3.8 пунктның беренче абзацында «ниятләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктта «квартал саен үсә барган нәтиҗә белән хисап кварталыннан соң килә торган 45 календарь көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктының тугызынчы - уникенче, унбишенче - егерме җиденче, утыз өченче һәм утыз дүртенче абзацларының гамәлдә булуы 2021 елның 8 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин